**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Село Янурусово, улица Ленина, дом 43а,
423370 Телефон 4-10-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**

Ленин урамы,43 а йорт, Янурыс авылы,
423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

РЕШЕНИЕ КАРАР

**19.03.2020г** **№4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Янурыс авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 24 августындагы 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Янурыс авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «Янурыс авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 24 августындагы 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 5 бүлекнең 1 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләргә идарә итү тәртибен (устав капиталындагы өлешләр) билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (акционер,катнашучы) муниципаль берәмлек булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

2) 4 пунктның 1 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;».

3) 12 бүлекнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

4) 12.1 бүлегендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында законнарын камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупцияле хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча кулланыла, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек чорларын, аның отпускта булуын исәпләмәгәндә һәм коррупцияле хокук бозу кылган көннән соң өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

Янурыс авыл җирлеге
Советы Рәисе                                                                 А.Ә.Мөхәммәдиева